**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның 23 сентябреннән № 1-2

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгын сайлау турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясына, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 40, 41 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы вазыйфасына тавыш бирү йомгаклары буенча хисап комиссиясенең 2025 елның 23 сентябрендәге 2 номерлы беркетмәләрен расларга (кушымтада бирелә).
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы итеп Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советыннан Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы депутаты Тарнавский Егор Александрович район Советы вәкаләтләре срогына сайларга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советының
беренче утырышында рәислек итүче
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Советының Шахмай авыл җирлегеннән депутаты Г.М. Сөләйманов